РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

423950, п.г.т. Уруссу, ул. Пушкина, д.38
тел.: (85593) 2-74-16, факс: (85593) 2-62-20

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

423950, Урыссу ш.т.б., Пушкин урамы, 38
тел.: (85593) 2-74-16, факс: (85593) 2-62-20


**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 21 » 09 2023 г. №1443

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 03 июлендәге 453 номерлы карары белән расланган, Ютазы муниципаль районы территориясендә алкоголь продукциясен сатуны тәртипкә салу һәм аның легаль булмаган әйләнешен чикләү буенча район ведомствоара комиссиясе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 26 гыйнварындагы 1-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 03 июлендәге 453 номерлы карары белән расланган, Ютазы муниципаль районы территориясендә алкоголь продукциясен сатуны тәртипкә салу һәм аның легаль булмаган әйләнешен чикләү буенча район ведомствоара комиссиясе турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.2. Комиссия үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә, Татарстан Республикасы Конституциясенә, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарына, Татарстан Республикасы Башлыгының (Рәисенең) указларына һәм күрсәтмәләренә, Россия Федерациясе Хөкүмәте, Татарстан Республикасы Хөкүмәте карарларына һәм күрсәтмәләренә, Ютазы муниципаль районы Уставына, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таяна.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында Дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының Бердәм Порталы составында «Рәсми Татарстан» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе С.П. Самонина